| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>АЛЕКСАНДРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>АЛЕКСАНДРОВКА<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Александровка авылы

2019 ел, 7 март №100

**Александровка авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 декабрендәге 93нче номерлы карары белән расланган «Александровка авыл җирлегенең 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты турында»гы карарга үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Александровка авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 декабрендәге 93нче номерлы карары белән расланган «Александровка авыл җирлегенең 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты турында»гы карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6нчы статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыруга Баулы муниципаль районы бюджетыннан күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга:

- төзелгән килешүләр нигезендә 2019 елга муниципаль учреждениеләрне карап тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә 2281,7 мең сум, 2020 елга 2203,3 мең сум, 2021 елга 2119,5 мең сум күләмендә;

- төзелгән килешүләр нигезендә 2019 елга авыл җирлегендә яшәүчеләрнең ялын оештыру һәм халыкка хезмәт күрсәтү өчен шартлар тудыру чараларын тәэмин итү өчен 1470,7 мең сум күләмендә, 2020 елга 1526,6 мең сум күләмендә, 2021 елга 1587,7 мең сум күләмендә мәдәният оешмалары хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү каралган.

2. 2019 елда Баулы муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертларны күчерү ай саен тигез өлеш белән башкарыла дип билгеләргә.»

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Александровка авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе И.Р. Вәлиев